



*Зөлфәт Хәким*

# Сентябрь алмалары

*Афоризмнар, шигырьләр, җырлар*



КАЗАН • ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ • 2004

УДК 820/89(470)
ББК 84(2Рос=Тат)–6
Х 86

**Хәким Зөлфәт**

Х 86 Сентябрь алмалары: Афоризмнар, шигырьләр, җырлар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. — 126 б.

Китапта танылган драматург һәм шагыйрь Зөлфәт Хәкимнең афоризмнары, шигырьләре һәм җырлары урын алды.

ISBN 5-298-01414-3
© Татарстан китап нәшрияты, 2004

# Уйлар
# уйнавы...





1

Нык яраткан кешеңнең кимчелекләре күренми, диләр... Шуңа күрәдер инде кеше үзенең бик күп кимчелекләрен күрми.

2

Бу тормыш дигән маскарадта битлекләр белән капланган чырайларның күренмәве, бәлки, яхшырактыр. Битлекләрне салдырсаң, дөнья тагын да ныграк караңгыланыр иде. Чын йөзне күрүемнән ни мәгънә?! Чын йөзе матур булса, ул аны битлек белән капламас иде. Монафикъ килеш калсын. Мин бары тик: «Синең икейөзлелегеңне күрмим, аңламыйм», — дигән ялган битлек киям... һәм, шайтан алгыры! — башкалардан аерылмый башлыйм. Күрәсең, бу маскарадта минем икейөзлелегем дә зарур.

3

Зарлан! Кешеләрдән. Дөньясыннан.
Зарлан! Рәхәтләнеп тыңлыйм. —
Миңа ләззәт бирә синең күңелеңнең
шакшы почмагына сәфәр кылу.

4

Мин, синдә үземне «күреп», котсыз калам. —
Мин шундый ямьсез микәнни?!

5

Беркем дә үзеннән акыллырак кешене яратмый. Шул сәбәпле акыллы кеше әңгәмәдәшенә караганда акыллырак күренүдән саклана.

6

Каракның бүреге яна, диләр. Дөрес түгел! Каракның бүреге яңа!

7

Тармаңгайлыктан дәва юк!

8

Бүгенгесе мактанырлык булмаса, кеше үткәне белән шапырына. Чөнки үткән заманны ялган белән бизәп матурлап була.

9

Иң куркыныч кеше — «без» дип сөйләшүче. Җаваплылыкны үз өстеннән төшерү ниятеннән ул һәрвакыт «Без шулай идек...», «без болай булдык, тегеләй иттек...», «без фәлән хаталар җибәрдек, без ялгышканбыз...» дияр. Җаваплылыкны өстенә алмас өчен, үз исеменнән сөйләүдән котылырга омтылучылар аркасында яңадан-яңа җинаятьләр һәм фаҗигаләр туа.

«Мин» дип үз исеменнән сөйләргә җөрьәт итмичә «без» дип лаф оручы бәндәләрдән куркыгыз!

10

Гомереңне кызганма, ул сиңа бушлай бирелгән.

11

Татар нәрсәне булса да аңламаса, бу милли түгел, безгә хас түгел һәм моңа мохтаҗлыгыбыз юк, дияр.

12

Мескен кешене тагын да ныграк буйсындырасы, сытасы, изәсе килә. Бу күренешне аңлата алмый җәфа чигәләр. Моның җавабы ап-ачык лабаса. Мескенлек — табигый түгел, гарип халәт, шул сәбәпле мескенлеккә карата кешедә йөгәнләп булмаслык нәфрәт уяна. Нишләп мескенне кызганмый соң ул? Кызганмый, чөнки аңының кай төше beләндер ул аңлый: мескенлек — барлык фаҗигаләрнең сәбәбе. Кеше үзенең табигате белән бу күренешкә каршы эчке сугыш игълан итә.

13

Күккә карап: «Бирче, Ходай!» — дигән кешенең дингә нинди мөнәсәбәттә булуын әле ачыклыйсы бар. Күккә «Бир!» дип оран салучы Аллага ышана микән?

14

Хәерче байны күралмый. Бай хәерчене күрми.
Хәерче бирә алмый. Бай бирми.

15

Прокурор җинаятьләр булмавын телиме?
Табиб авыруларның бетүен телиме?
Генерал сугышларның булмавын телиме?
...Ә син үзеңнең булмавыңны телисеңме, юкмы?!

16

Чынбарлыкны бер син генә түгел,
Хәтта дөнья үзе җиңә алмый.

17

Яшәүнең мәгънәсе — яшәү мәгънәсен эзләү.

18

Импотент дәртле кешене әхлаксыз дип оялтырга тырышыр.

Чирле кеше хәмер эчүчене сүгәр.

Булдыксыз кеше эшмәкәрне комсыз дип битәрләр.

19

Иң әйбәт кеше — үлгән кеше. Аның дәгъвасы юк, берни сорамый, комачауламый. Шуңа күрә үлгән кешене яраталар.

20

Ул халык өчен көрәшә, дисез. Әмма ләкин озак көрәшүчене түгел, ә бәлки җиңүчене мактарга кирәк. Көрәшүчеләр күп. Җиңәргә кирәк! Мәңге көрәшүдән ни мәгънә?!

Сабантуйда озак көрәшүчене түгел, җиңеп батыр калучыны данлыйлар!

21

**Килү. Китү.**

**Китү — килүгә** караганда гүзәлрәк һәм илһамлырак күренеш. **Килүдә** үзеңне-үзең коллыкка илтү чагылышлары күп. Җиңүче булып килгән суратттә дә килү халәте үзеңне башка урын, башка мохит, чит-ят кешеләр белән бәйләнешкә керергә мәҗбүр итә. Бу очракта да син ирек-

ле түгел. Килүдә чарасызлык күбрәк түгелме? Хәтта хәерче дә кулын сузып **к и л ә** ләбаса.

**Китү** исә көчле рух ияләренә хас. Бар нәрсәгә төкереп, ирексез итеп тотучы вак-төякне, чүп-чарны җыеп түгеп, араларны мәңгегә өзеп китеп бару — бөек күренеш! Китүдә азатлыкка омтылу һәм өметнең канат җәйгән мизгеле бар! Ә инде вакытында китү — даһи күренеш һәм вакыйга!

Көн саен кем беләндер, нәрсә беләндер мәңгегә хушлашу мәслихәт! Бер урында озак тору, тыгыз элемтәләр кору ярамый. Аерым бер мохиттә казынучы булып, һаман да ниндидер бер көйгә биеп, югалтудан куркып (кемне, нәрсәне?!), вак мәшәкатьләрнең колы булып яшәү — үлеп баруга тиң. Эчке үлем бугазыңа таба үрмәләгәнче китәргә кирәк, китәргә!

Килсәң дә, **к и т ә р** өчен килергә кирәк!

Мин килмәдем. Минем үтеп барышым. Сезгә таба атлаганда, бәлки, моны килүем дип аңлагансыздыр. Юк, бу — **к и т к ә н д ә** үтеп баруым. Шул арада сезне күрдем. Аңладым. Һәм, ниһаять, китеп барам. Шушы түгелмени бәхет — сезнең белән калмыйм, китәм, китәм, китәм!

Чөнки минем үләсем килми!

22

Ялкауны битәрләмәгез.

Чирле кешене чирләгәне өчен ачуланмыйсыз бит...

23

Мин сине дуэльгә чакырмакчы идем. Кинәт тетрәнеп киттем һәм бу ниятемнән оялып куйдым — мәеткә ату хурлык лабаса!

24

Балыкның кайнар табага элэгүендә кармактагы суалчанны гаепләргә маташучылар да бар.

25

**Каһарман** куркак булудан курыкканга күрә курыкмый.

26

Сау бул! Синең белән хушлашуның рәхәтлеген татыр өчен генә дә бу дөньяга килү ярый.

27

Алда үлем көткәнгә күрә генә яшәү мәгънәгә ия.

28

Үткәннәре түгел, бүгенгесе бөек булса гына халык бөек санала.

29

Банкет — хәерчеләр, ялагайлар һәм шамакайлар оҗмахы.

30

Ялгызлыкны күтәрерлек көче булмаса, кеше дус-иш эзли, төрле мәҗлесләргә йөгерә, халык арасына керергә тырыша. Шулай итеп, ул эчке бушлыгын ни белән булса да тутырырга маташа. Ә ялгызлыкта калса, андый кеше үзенең төпсез бушлыгына егылып төшәчәк.

31

Кеше икәнлегеңне тәкрарлап маташма, барыбер исбатлый алмаячаксың. Исбатлауда мохтаҗлык бар икән — ышандырган суряттә дә шик калачак.

Хайван түгеллегеңне исбатласаң, шул җиткән. Ләкин, әйткәнемчә, исбатларга мәҗбүр чиккә җиткәнсең икән инде, барыбер кемдә булса да шик калачак.

Ә син исбатлама! Шул чагында Кеше икәнлегеңә ышаначаклар.

32

Һәркем үз эшен изгеләштермәк була. Моның өчен ачуланмагыз. Үзен-үзе алдап, кеше яшәвен мәгънәле итеп күз алдына китерә.

33

Моның хәле бөтенләй үк хөрти түгел — аның яшисе килә.

Тегенең дә алай ук чарасыз дип әйтмәс идем — аның үләсе килә.

Ә менә монысына нишләмәк кирәк — яшисе дә килми аның, үләсе дә?!

34

Яшәү юк!

Үлемнең вакытлыча булмый торуы гына бар.

35

1917 ел — нәтиҗә! Сәбәп түгел!

36

Үзе өчен көрәшә алмаган кеше халык өчен көрәшә алмый.

37

Аллага үзләренә кирәк чакта гына ышанучы кешеләр арасында яшим мин.

38

Һәрнәрсәнең сәбәбе бар. Йә Ходаем, син дә нәтиҗә микәнни?!

Хәер, син сәбәп булсаң, яхшыракмыни?!

39

Син үзеңне яратуларын телисең. Ә нишләп әле сине яратырга тиешләр? Шулай да сиңа шанс бирелгән. Колагыңа гына әйтәм: яратырлык итеп үзеңне үзгәртергә әле вакытың бар. Хәлеңнән килерме, юкмы — анысы башка мәсьәлә.

40

Кемнеңдер эшен хурлау, яманлау — хөсет, булдыксыз һәм мескен кеше шөгыле. Бу аның бердәнбер чарасы. Хыялында үзеннән өстен кешене «бәреп төшерү» аңа вакытлыча ләззәт һәм канәгатьлек бирә.

41

Гадәттә көчсез һәм үзенең сәләтенә ышанмаган кеше төрле оешмаларга керергә омтыла (союз, клуб, җәмгыять

һ.б.). Анда аңа тынычрак. Өстәвенә үзендә җитенкерәмәгән нәрсәне уртак казаннан чумырып алырга нияте дә бар.

42

Кем эшләми, шул ашәми.

43

Биек мәчет манаралары һәм башка төрле купшы гыйбадәтханәләр, сарайлар төзүне Алла ничек кабул итәдер?.. Аллага затлы, биек биналар түгел, ә бәлки кеше үзе әһәмиятледер. Алланы күпсанлы ялтыравыклы гыйбадәтханәләр түгел, кеше үзе кызыксындырадыр.

44

Мәхәббәте аз булган кеше мәхәббәт турында күп сөйли.

Яратырга сәләтле кеше сөйләми. Ул ярата.

45

Коллар илендә хакимнәр дә — коллар. Хакимнәре коллар булганга күрә коллар иле бит бу!

46

Көнләшү — мәгънәсезлек. Әгәр хатының хыянәт итә икән, көнләшеп бернишләп булмый, бернәрсәне үзгәртү мөмкин түгел.

Әгәренки хатының хыянәт итми икән, бу очракта көн-

ләшү бөтенләй урынсыз. Кыскасы, ике очракта да көнләшүдән мәгънә юк.

Ә бит шушы ике очрактан кала башка очраклар юк! Димәк, көнләшү, ничек карасаң да, һәрвакыт мәгънәсез!

47

Күзләреңнән укыйм, син миңа сорау бирмәкче буласың: «Башкалардан бәхетлерәк булырга сиңа кем рөхсәт бирде?»

Син — кол. Беркайчан да минем кебек ирекле булмаячаксың. Чөнки башкалардан бәхетлерәк булырга хакың юк, дип уйлаучы үзем дә бәхетле булырга хаксыз, дигән эчке канун белән яши.

48

«Ул үзен генә ярата», — дисең. Аның кешеләрне яратмавына килми синең ачуың. Ул сине яратмый, шул сәбәпле син аны күралмыйсың. Аннары син аның шикелле үзеңне-үзең оста һәм шаккатарлык итеп яратырга сәләтле түгел. Шуңа күрә нәфрәтең тагын да бермә-бер арта.

49

Китап сүзе белән генә сөйләүчеләр — кешелекне артка таба сөйрәүчеләр.

50

Язучы икәнсең, бу синең шәхси проблемаң. Бүләкме бу сәләт сиңа, әллә, киресенчә, җәзамы — үзең өчен үзең хәл ит. Кешеләрдән дан, мәхәббәт таләп итмә, берни дәгъвалама. Син иҗатчы булуда кешеләр гаепле түгел.

51

Җинаятьче үзенең яман эш кылуын *аңламый*, җинаятенең асылына, аның сәбәбенә төшенми. *Аңласа*, ул җинаять кылмас иде.

Нәрсә өчен хөкем итәргә кирәк икән аны: кылган җинаяте өченме, әллә *аңламаганы* өченме?..

Мөгаен, җинаяте өчендер. Әмма ләкин бу бит асылда *аңламаганы* өчен хөкем итү булып чыга. Ә бу ярый торган эшме соң?!

52

«Куприн, Аксаков, Карамзин һ.б., һ.б. — татарлар», — дип мактанырга яратасыз. Бәлки, кайгырырга кирәктер? Бу татарның фаҗигасе ләбаса!

53

Нишләп мескен кеше үлемнән ныграк курка?
Шул куркак булганга мескен дә инде ул.

54

Мәңгелек турында бик еш сүз катасың. Язган әсәрләреңнең киләчәге хакында кайгырасың...

Җавап бирче: мәңгелектә исемең калу сиңа нигә кирәк? Һәм дә синең исемең мәңгелеккә ни бирә, нәрсә өсти? Дөньяга, кешеләргә нинди мөнәсәбәттә булуың, дөньяга карашың — синең шәхси проблемаң. Шуңа күрә бу дөньядан киткәндә, исемеңне дә, үзеңнең дөньяга карата меңләгән мөнәсәбәтләреңне дә, хәтта чишелмәгән проблемаларыңны да үзең белән алып кит. Синнән соң яшәүчеләр дә синең кебек матур, көчле, сәләтле, үзгә һәм кабатланмас шәхесләр.

55

Китәм, дисең...
Синең китүең белән китмәвең арасында аерма бармы соң?!

56

Юл кагыйдәсен бозуларын иң нык теләүче кеше — ГАИ инспекторы.

57

Гаепне башкалардан эзләмә. Ул бары тик синең үзеңдә.
Дөреслекне дә читтән эзләмә. Анысы инде күптән үзеңдә.
Ә үзеңнән читтә нәрсә бар соң? Бары тик синең кебек эзләүчеләр генә.

58

Нишләп Рәсәй рәтле тормыш кора алмый?
Чөнки Ватан хисе юк. Бер халык та бу илне үз Ватаны дип санамый.

59

Сез һәрвакыт нәтиҗә белән сәбәпне бутыйсыз. Тормыш начар булганга күрә, халык *шундый*, дисез.
Дөрес түгел. Киресенчә, халык *шундый* булганга, тормыш начар!

60

Берәү үтерү хәленнән килмәгәнгә үтерми.

Икенче берәүнең үтерергә кодрәте җитә, әмма ул вәхши түгел, шуңа күрә үтерми.

Минем өчен икенчесе кыйммәтрәк.

61

Элек яшәгән шәхесләрне ныграк яраталар, аларга хәтта табыналар.

Бу күренеш, асылда, бүген яшәүче шәхесләрне күрмәмешкә салышу, инкарь итү, алардан көнләшү галәмәте.

62

Сугышта ике як та гаепле. Берсе сугыш башлауда гаепле. Икенчесе — сугыш башларга ирек бирүдә.

63

Медальләргә, орденнарга, премияләргә кызыгучы кешенең, онытылып, берәр медаль хакына Ватанын сатуы ихтимал. Хәер, андый кешенең тумыштан ук Ватаны булмый бугай.

64

Мәдәниятне, телне, тарихны, фәнне, мәгарифне күтәрергә кирәк дисезме?

Иң элек үз дәүләтеңне булдыру кирәк. Бит иң әүвәле йорт салалар. Шуннан соң гына аны җиһазлыйлар, бизиләр һәм гаилә үз тормышы белән яши башлый. Йорты булгач, анда казаны да кайный, җыры да яңгырый.

65

Минем бәйсезлегемне син авыр кабул итәсең. Сизәм, хөрлегемнең серен беләсең килә.

Сере гап-гади. Син үзеңне шушы гомереңә, менә монда теркәп, бәйләп куйгансың һәм аяк астыңдагы чүплектә казынасың. Ә мин исә Мәңгелектән Мәңгелеккә үз иманым белән сәфәремне дәвам итәм. Син казынып ятканда, мин офыктан офыкка таба үтеп барам.

Син — Вакыт колы, авыр сулап: «Гомер үтә», — дисең.

Ә мин үзем үтеп барам! Гомер түгел, мин үзем үтәм.

Аңлыйсыңмы?

Аңлау гына да аз шул әле...

66

Сиңа карата мөнәсәбәтемне беләсең киләме?

Дошманым булалмыйсың, чөнки син вак һәм түбән кеше.

Дустым булыр идең, ләкин мөмкин түгел, чөнки моның өчен сиңа сасы чокырдан чыгып чистарынырга кирәк.

Сиңа карата битараф булыр идем, әмма ләкин битарафлык үлгән кешегә генә хас.

Шулай да, әйдә, дошманым бул! Бу очракта мин сине юк итәчәкмен! Һәм шулай итеп, мәсьәлә дә хәл ителә.

67

Күңел хәерчелеге бүләкме, җәзамы — миңа, мәсәлән, мәгълүм түгел.

68

Мәхәббәтнең азагы бар.

Нәфрәт тә берзаман сүнә.

Бары тик битарафлыкның гына чиге юк. Чөнки ул Кеше хисе түгел. Кеше күңеленә хас хис-тойгылар, кичерешләр генә чикле була. Битарафлык исә күңел халәте түгел, ул фәкать мәхәббәтнең дә, нәфрәтнең дә юклыгы. Ә мондый халәт... мәеткә генә хас.

69

Җинаятьченең җинаять кылырга иреге бар. Чөнки Күк тарафыннан ук ирекле итеп яратылган.

Аның җинаять кылмаска да иреге бар.

Кеше үзе хәл итә — җинаятьне кылыргамы, юкмы. Ул — ирекле.

Җинаять кылган очракта аның хөкем ителеп җәза алырга да иреге барлыкка килә. Аның хәтта үлем җәзасына хөкем ителергә дә иреге бар.

Тирәнрәк уйлап баксаң — куркыныч! Кешенең сайлап алырга хакы бар — җинаять кылыргамы, юкмы.

70

Әшәкелегеңне, начар сыйфатларыңны, күңелеңнең пычраклыкларын күрсеннәр өчен күп нәрсә кирәкми. Бары тик соры халык төркеменнән өскәрәк калку мәслихәт. Һәм меңләгән адәм актыклары сине: «Адәм актыгы!» — диячәк.

71

«Кешеләрне яратам!» — дигәннәрен еш ишетәм. Болай дип оран салучы үзенең әйткән сүзенең мәгънәсезле-

ген һәм мәнсезлеген аңларлык дәрәҗәдәге акылга ия түгел, әлбәттә. Аңласа, ул алай димәс иде.

Минемчә, кешеләрне, гомумән, яратырлык түгел. Гомумән алганда, инсаният мәхәббәткә лаеклы түгел. Аерым алган кешеләрне генә ярату мөмкин. Аерым алган шәхес бөтен кешелек дөньясына караганда кызыграк. Моңарчы яшәп килгән әдәбият, сәнгать тә бит аерым кешеләр турында иҗат ителгән. Халык төркеме түгел, шәхес кызыграк. Әле бөтен дөнья халкы турында әсәр иҗат иткәннәре юк.

Бөтен инсаниятkә мәдхия җырлаучы, минемчә, шәхесләрдән «качар» өчен, алардан үзе өстен булу нияте белән яки аерым алган кешегә ярдәм итәргә теләмәүдән (һәм көченнән килмәүдән) «халык», «кешелек дөньясы», «кешеләр» дигән һ.б. төшенчәләр белән сату-алу итә.

72

Куркытучының куркытуында куркучы үзе гаепле.

73

Тавышын ишетеп һәм күзләрен күреп, кешенең кем икәнлеген әйтеп була.

74

Саран кеше иң әүвәле үзенә карата саран була.

75

Бездә хайваннарны яратудан түгел, ә бәлки кешеләрне күралмаганга эт асрыйлар.

76

Хатынының барлык уйларын белсә, ире аны шул көнне үк аерыр иде.

77

Трусигыңны юган хатын кайчан булса да сиңа әшәке сүз әйтми калмый.

78

Кешене үзенең хәерчелеге түгел, ә бәлки башкаларның аңа: «Хәерче!» — диюләре куркыта.

79

Мактасалар, ышанма.
Хурласалар, ышанма.
Эндәшмәсәләр, ышан — сине йә мактарлык, йә хурларлык.

80

Син матур, дисәләр, димәк, син матур.
Син ямьсез, дисәләр, димәк, син бик матур.

81

Ул хатын күңелеңнең бер өлешен үзе белән алып китте, дисең. Моның белән хәтта горурланасың. Ә син үзеңә сорау биргәнең бармы: күңелеңнең ул өлешен мәңге үзе белән йөртерме, әллә берәр сасы чүплеккә ташлап калдырырмы?..

82

Безне өмет яшәтә. Ә өмет өзелгән чакта нәрсә яшәтә? «Әле өмет кабыныр...» дигән өмет, ахрысы.

83

Исемеңне мәңгеләштерергә хыялланасыңмы? Сине бу дөньяда бар иткән Алладан бераз читенсенер идең! Ул бит синең бу ниятеңнән бары тик көлә генә.

84

Үзеңнең чын бәяңне, урыныңны белер өчен, должностеңны, әшнәләреңне, кодаларыңны, таныш-белешләреңне, акчаңны — барысын да читтә калдыр да, ялгызың яшәп кара.

85

Бәхетсез гаилә — «Кеше гаилә корып яшәргә тиеш!» дигән канун буенча өйләнү нәтиҗәсе. Гаилә тормышына эчке ихтыяҗ булмаган килеш гаилә коручылар аркасында киләчәк буыннар михнәт чигә һәм фаҗигаләргә дучар була.

86

Кайвакыт урамда эт өрсә дә кәеф бозыла.

87

Хәерче илдә шагыйрьләр күп була.

88

Һәркем шагыйрь. Һәркем җырчы.
Аерма фәкать сыйфатта гына.

89

Нәрсә ул бәхет?
Бәхет — бәхетсезлектән арынып торган мизгел.

90

Минем гомерем бик сәер вакытка туры килде. Бердәнбер котылу чарасы — вакыт үзе... Сәер түгелмени?!

91

Мин һәрвакыт күз карашымны иркәләгәнгә һәм күңелемә хуш килгәнгә гашыйк булдым.
Мин беркайчан ямьсезлеккә гашыйк булалмадым.
Шулай булгач, ничек мине яхшы кеше дип әйтсеннәр?!

92

Монда үлем бөек сер түгел.
Монда үлем — чара.

93

Монда яшәүгә каршы көрәшкәндә генә, яшәү мәгънәле була.

94

Монда: «Бер яңагыңа суксалар, икенчесен куй», — диләр һәм шул вакытта башыңны чабып ташлыйлар.

95

Мәңгелек дан турында хыялланмагыз! Алла гына мәңгелек. Ул үзенә үз куллары белән конкурент яратмас бит инде.

96

Кояшның чыкканын күргәнем бар.
Минем аны мөнбәренең иң югары ноктасында күргәнем бар.
Кояшның мин баеганын күргәнем бар.
Ләкин минем аны баеганнан соң күргәнем юк. Шуңа күрә ул минем өчен көн саен яңалык һәм көтелмәгән булып чыга.

97

Һәрбер сагыну — үзеңне сагыну.

98

Тормыш авырлыгыннан түгел синең явызлыгың, ә бәлки шул авырлыкны җиңә алмаганыңнан.

99

Бу дәүләт мин начар булсын өчен бөтен көчен куйды. Хәзер инде ул үзен начарайтуга бөтен көчемне куюдан курыксын.

100

Туган бала — ата-ананың уй-ниятләре, дөньяга мөнәсәбәтләре, күңел халәтләре нәтиҗәсе. Тәрбия нинди әһәмияткә иядер, белмим. Ләкин, минемчә, ата белән ананың кавышкан чакларында ук карында барлыкка киләсе бала «ясала» башлыйдыр. Һәм дә бала табу — поступок, кешенең бөек карары. Тирәнрәк уйлап баксаң, бу карар — йә гөнаһ нәтиҗәсе, йә савaплы эшләр гамәле.

101

Көзгедәге сурәтемә ышаныр өчен, мин көзгегә ышанырга тиеш. Нинди бәйлелек! Нинди әсирлек! Нинди көчсезлек!

102

Син тормышны сүгәсең. Димәк, үзеңнән канәгать түгелсең. Тормышны сүгәрлек икән, димәк, үзеңне сүгәрлек.

103

Үз көчеңне дөрес чамаламау сәбәпле, күпме фаҗига туа.

104

Гади генә итеп кешеләрне яхшыларга һәм начарларга бүлүчеләр аркасында бу дөньяда гаделсезлек хөкем сөрә.

105

Берәр тавыш ишетелсә, як-ягыңа карарга ашыкма. Иң элек үзеңә колак сал — синең үзеңнән килмиме ул аваз.

106

Өндәүчегә игътибар белән карасаң, күрерсең: кешеләрдән үзендә җитенкерәмәгән сыйфатларны таләп итә ул.

107

Җан газабыннан җан бизү коткара ала.

108

Талант — бүләк түгел, талант — җәза.

Чын иҗат кешеләре арасында бәхетлеләрен күргәнегез бармы?!

109

Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең ясалмалылыгы гына ясалма түгел.

110

Кеше гомере — юл. Үзеңнән үзеңә.

111

Халыкның сабырлыгыннан политиклар файдалана.

Халыкның куркаклыгыннан уголовниклар файдалана.

Халыкның наданлыгыннан язучылар файдалана.

Нинди бетмәс-төкәнмәс файда хәзинәсе ята синдә, халкым!

112

Бернәрсәнең, бернинди төшенчәнең кадере калмады... Аптырамагыз, нәрсәнең дә булса кадерен табачаклар.

113

Үзенә: «Нишләп соң мин кешеләрне күралмыйм?» — дигән сорауны кешеләрне чынлап яратучы кеше генә бирә ала.

114

Кешене нindидер тискәре сыйфаты өчен ачуланганчы, иң элек «Нигә андый соң ул?» дигән сорауны бирү мәслихәт.

115

«Милләтне коткаручылар»дан кайвакыт милләтне коткару кирәк.

116

Сугыш ерагайган саен, сугыш ветераннары күбәя бара.

117

Бай кешегә малы хезмәт итә, ә хәерче исә үзенең барлы-юклы малының колы булып яши.

118

Мәгънәсезлекнең мәгънәсен эзләүдә мәгънә бар.

119

Үлем барысын да үзе белән алып китәчәк: даһины һәм гадине дә, байны һәм хәерчене дә, түрәне һәм колны да...

— Монда кем калачак соң?

— Даһилар һәм гадиләр, байлар һәм хәерчеләр, түрәләр һәм коллар...

120

«Мин дөрес юлдан бармыйм, ахрысы», — дип, дөрес юлга аяк баскан кеше әйтер. Шулай дип әйтүе — аның бу юлда ясаган беренче адымы булыр.

121

Гомернең тулаем алганда мәгънәсе юк. Ләкин аны мәгънәле итү мөмкин. Яшәвеңне мәгънәле итәргә омтылу зур мәгънәгә ия.

122

«Милләтне бетерәсез!» — дип чәчрәп чыгучы — милләтне бетерүгә иң зур өлеш кертүчеләрнең берсе.

123

Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясен кемнәр алганны белсә, Габдулла Тукай үзе йә премия исемен үзгәртүләрен таләп итәр иде, йә булмаса, хәтта үзенең исемен үзгәртүгә барыр иде.

124

Дөньяда иң бөек бунтарь — ялган акча ясаучы.

125

«Безгә ирек бирмиләр, безне танымыйлар, кыерсыталар, кысалар», — дип елаучыга беркайчан ирек бирмәячәкләр, аны беркайчан танымаячаклар, һәрвакыт кыерсытачаклар һәм кысачаклар. Кешелек дөньясы вәхши — беркем беркайчан беркемгә бернәрсә китереп бирми.

126

Мескен чакта мескенлеген җиңәргә омтылучы мескен түгел!

127

Начар кешеләр юк. Бары тик синең күңелеңә хуш килмәүчеләр генә бар.

Яхшы кешеләр дә юк. Фәкать синең күңелеңә хуш килгәннәре генә бар.

128

Минем иҗатымны, яшәү рәвешемне тәнкыйтьләр өчен иң элек минем хөрмәтемне яулап ал, минем алда абруй казан.

Мине тәнкыйтьләргә хакың юк, чөнки син мине ашатмыйсың, миңа хезмәт хакы түләмисең.

Гомумән, әгәр дә мин сине үзем яратмыйм икән, синең мине ачуланырга хакың юк.

129

Синең бүләк алуыңа сөенүчеләр бардыр.

Шулар арасында бүләккә лаеклы булганыңа сөенүчеләре бар микән?

130

Дәртле һәм дәрманлы чакта кеше үзен Алла дип хис итә.

Йончыган һәм хәлсезләнгән чакта аңа Алла кирәк.

131

«Бетәбез!» — дип, гадәттә, үзенең бетеп баруын сизүче кычкыра.

132

Һәр кеше язмышы өчен барлык кешеләр җаваплы. Кеше туа, дөньяга килә һәм аңа кадәр уйлап чыгарылган кануннар, башка кешеләр калыплаштырган яшәү рәвеше аны «әсир итә». Аңа кадәр яшәгән кешеләр кабул иткән кагыйдәләр буенча яшәргә мәҗбүр дөньяга туган яңа кеше. Шуңа күрә аның гамәлгә ашкан һәр эше өчен бөтен халык җаваплы. Җаваплылык, җаваплылык, җаваплылык! Моны онытмаска иде!

133

Башка кеше кайгысыннан елаучыны югары дәрәҗәдәге әхлаклы кеше дип санарга ашыкмагыз.

Чит кеше шатлыгыннан күз яшьләре кипкән кешене исә югары, бөек әхлаклы шәхес дип атарга була.

134

Кайвакыт ихлас күңелдән әйтелгән бер җылы сүз романнардан, повестьлардан, шигырьләрдән, җырлардан кыйммәтрәк, кирәгрәк, сихәтлерәк була.

135

Мин көнчелектән үсмер чагымда ук арындым.
Хәзер дан-шөһрәткә омтылудан арынып киләм.
Йа Ходаем, калган гомеремдә дә мине *арыну* сәләтеннән арындырма!

136

Тирән акыллы кеше өчен Җиһан бер киңлектә, сай акыллы кеше өчен — башка киңлектә.

137

Кеше һәрвакыт иртәгәсе көнне зарыгып көтә. Үзе һәрвакыт гомер тиз үтә дип зарлана.

138

Актер моннан күп еллар элек яшәгән классик драматургның әсәрендәге рольне башкарырга хыяллана.
Әгәренки ул драматург исән булса, үзенең әсәрендә бу актерның уйнавын теләр иде микән?..

139

Актриса чибәр булырга тиеш. Тискәре персонажны да матур актриса уйнарга тиеш. Бигрәк тә хәле мөшкел мил-

ләт театрларында затлы, мәһабәт гәүдәле, чибәр актрисаларның булуы зарур.

140

Татар халкы бердәмсезлегенең төп сәбәбе — генетик яктан «чуар» булу. Татар — төрле халыклардан җыйналган милләт.

141

Кемдер аңлы рәвештә зыян китерә, кемдер файда эшлим дип зыян китерә, кемдер зыян китерәм дип, аңсыз рәвештә файда китерә, кемдер аңлы рәвештә файда китерә.

Боларның барысын да кеше үзенә файдага эшләргә тырыша. Ләкин кайвакыт үземә файда эшлим дип, үзенә зыян гына китерә.

142

Кол гына көрәшә.
Хөр кеше көрәшми.
Иң бөек көрәш — үзеңдәге эчке колга каршы көрәшү.

143

Трибунага милли ахмак менеп кычкыра башласа, милли хәрәкәт бетте, шушы вакыттан милли конвульсия башланды дигән сүз.

144

Милләтнең тормыш уклады сакланмаса, милләтне дә саклап калу мөмкин түгел. Милләтне милли тормыш уклады саклый.

145

Иҗатчы эзли. Димәк, әлегә хак юлны тапмаган. Аның иҗаты — эзләү. Тапса, иҗат итүдән туктар иде ул. Шуңа күрә аның һәр сүзе, һәр фикере — субъектив һәм бәхәсле. Чөнки иҗатчы — *эзләүче*. Ул әле *тапмаган*.

146

Чакырылмаган кунак чакырылганыннан да яманрак.

147

Күккә карап Алланы эзләмә.
Үзеңне эзлә.
Алла югалмый.
Син генә югала аласың.

148

Яратуыңны яратмасалар, яратырлык итеп ярат.

149

Кеше тугач ук гаделсезлек дөньясында яши башлый. Бәлки, бу иң зур гаделсезлектер. Дөньяга килгән бала инде ул туганчы ук башка кешеләр тарафыннан уйлап чыгарылган кануннар, аңа кадәр яшәүчеләр урнаштырган тәртипләр буенча яшәргә дучар ителә. Һәрбер инсан үзеннән алданрак туучылар бар иткән мохиткә килеп эләгә. Һәм, ниһаять, кеше аңарчы төзелгән ил-көндә яшәргә мәҗбүр.

Шуңа күрә барлык кылган эшләре, гамәлгә ашкан уйниятләре өчен кеше берүзе генә җавап тотарга тиеш түгел.

150

Мәхәббәте юклыгын тойган кеше, гадәттә, мәхәббәт иясе була.

151

Һәркем үзенең эчке дөньясында яши. Кешеләр арасында кемдер патшаны, кемдер хезмәтчене, кемдер даһины, кемдер гадине уйный. Асылда исә һәрберсенең эчке тормышы бар — анда аның үзенең чын кайгысы, чын шатлыгы, үз бәхете, үз фаҗигасе кайный.

152

Кеше нәрсәне яхшы дип саный?
Үзенә кирәкне.

153

Акыллы кеше беркайчан да тинтәкне «уйный» алмас.

154

Яратуны пропагандалауда мәгънә юк. Ярату чакыру вә өндәү нәтиҗәсендә тумый да, яшәми дә.
Ярату юк чагында, яратырга сәләт югында аны пропагандалый башлыйлар.

155

Ата-ана баланы яратмаса, бала аларны яратмый. Баладан барыбер ярату таләп итәләр. Яратмаганнары өчен яратсын микәнни?!

156

Хакыйкатьне хакыйкать дип тәкъдир итү хакыйкатькә кирәкми дигән хакыйкатьне аңлар вакыт!

157

Ярдан ярга, ярсу-ярсу,
Яргалана агымсу;
Яна йөрәк!
Ямансу!
Ялагайдай ялап ала,
Ялган яла яга-яга,
Ярга ятып кага-кага, —
Ялган елга буйлап ага.
Яна йөрәк!
Ямансу!
Ярам яртышар ярмаса,
Яман ялган дәрьясында
Кай якларга агыйм соң?!

158

Биргәнне алуга караганда, алганны бирү авыррак.
Алганны бирмәүгә караганда, биргәнне алмау авыррак.

159

Хөкем итүчене хөкем итәргә кирәк диючене хөкем итү — әле барыбер хөкем ителергә тиешле кешене ачыкламый.

160

Мәхәббәт һәм Нәфрәт арасында мәхәббәт һәм нәфрәт болыны.

161

Тустагандагы кымызның
Тәмен белми тустаган;
Кайберәүләрнең күңеле
Тустаганга охшаган.

162

Хәтта үзенең кечкенә икәнен аңлаучы да барыбер әле кечкенә булып кала.

163

Арабызда ара арткан саен,
Җанга якын синең чыраең.

164

Асыл егет асылынмый
Асылташлар хакына,
Асып булмый андый әҗәл
Егетнең асылына.

165

Дошманның дошманын әгәр дошман итсәң,
Берсе дус булыр дип ышанма.
Ике дошман хасил булмагае.

166

Ялагай яра яламый.

167

Томана томанга күнеккән.

168

Кешенең күңел халәте чыраена языла.

169

Үзеңнең үзәгеңдәге үзгәрешеңнең үзенчәлеге — үзеңнеке генә.

170

Физиклар, химиклар фәнни-техник прогресска ирештеләр. Моның өчен аларга рәхмәт укып булмый. Бу «прогресс» асылда инсаният дөньясына каршы. Бу «прогресс» тормышны җайлау, җиңеләйтү нияте белән, телиме-юкмы, кешене үтерәчәк, бетерәчәк.

Физик белән химик күз яшенең составын аңлатыр, ә күз яшенең табигатен, сәбәбен, асылын аңлата алмас.

171

«Ирекле секс» нәселләрне һәм ахыр чиктә милләтләрне бетерәчәк.

172

Башка кешене яратырга сәләтсез кеше үзе дә мәхәббәткә лаек түгел. Ләкин аның монда гаебе юк.

Башка халыкларны яратмаган халык та үзен яратуга лаеклы түгел. Тик халыкның монда гаебе юк.

173

Кайвакыт хаклы кешенең хаклылыгын исбатлар өчен, аны хаксыз диючененең хаксызлыгын исбатлау да җитә.

174

Сыгыш сынмаган сыныңны
Сугыш сындырырлармы?!

175

Атымны югалтмас өчен
Атландым атка.

176

Янгын җылысыннан җан өши.

177

Сыздырыш уйнаган көйне
Сызгырыш туктатмассың.

178

Ачуымны ачсам, ачуланма —
Ачмый калсам, тагы да ачылана.

179

Көйсез көен көйләгәнче,
Җүнсез җырын җырлагыз.

180

Төн белән көн арасында сызык булмый;
Бу җиһанның бер төшен дә сызып булмый.

181

Кичәге син бүгенге син түгел,
Иртәгәге син — бүгенгесе түгел.
Син үзеңне беркайчан да «тоталмыйсың».

# Шигырьләр



* * *

Кычкырды төн!
Колакларны тондырып.
Томаланды дөнья.
Якты көтә караңгылык арасыннан,
Әллә кая качты гаугa яктылыгы,
Куркып шуны тынлык авазыннан.

* * *

Шаулама! Чү! Куркытырсың.

Төнгә муенын сузган
Кое сиртмәсенә куныш,
Ай үзен карый судан.

Боза күрмә бу тынлыкны,
Атлама бер адым да.
Күрәсеңме:
Ай бизәнә
Ерак сәфәр алдыннан.

* * *

Үтте көн —
Янды да бетте
Вакытның бер күпере.
Тау өстендә шәфәкъ булып
Балкый утлы күмере.

Бер-бер артлы сүнә көннәр,
Булмый саклап калдырып.
Кире юл юк үткәннәргә —
Үзе чыккан күперләрне
Китә вакыт яндырып.

*1989*

* * *

Аккан суның һәр тамчы-мизгеле
Мәңгелеккә таба юл ала;
Бик ямансу...
Күңел ымсына да
Елга җырын тыңлап юана.

Тугангамы Чулман буйларында,
Аккан кебек ул гел кыйблага;
Шуңа, ахры, зәңгәр су өстеннән
Мәңге җырлап туймас моң ага.

* * *

Күзли галим атом ядрәләрен,
Иелгән ул, нидер җуйган сыман,
Экраннарда сикерешеп бии саннар,
Сыекчадан күтәрелә куе томан.

Эзли галим сорауларга җавап,
Яшәешнең серен, очын таба алмый.
Нәрсә соң бу?! Нишләп зиһен җитми, —
Бер тамчыда нигә дөнья кайный?!

Шулчак галим карый йолдызларга,
Ярдәм эзли, ятим калган сабый кебек.
Бер уй аны сискәндерә: кемдер Күктә
Микроскоптан Җирне карый кебек.

*1989*

* * *

Мәхәббәт дип уйлама син бу газапны,
Күңелеңдә булсын һәрчак шөбһә-тимгел.
Ерткыч теләк читлегеннән чыкмак була,
Икебезгә вәгъдә итеп рәхәт мизгел.

Алданырбыз (ничәнче кат!) шул вәгъдәгә,
Чыгарырбыз читлегеннән... һәм шашарбыз.
Ерткыч басар сусауларын, безне эчеп,
Тынычланыр!
Һәм калырбыз яртышар без.

Бәргәләнер теләк тагын, үкереп, ярсып,
Бербөтенгә безне кабат кушам дияр.
Безгә ләззәт тою янә насыйп булыр —
Бер мизгелгә дөнья алсу күлмәк кияр.

Кабатланыр менә шулай күп мәртәбә,
Яну, сүнү берсен-берсе алмаштырыр.
Мәхәббәтнең үзен генә тоталмабыз,
Хисләр, сүзләр безне тагын адаштырыр.

Мәхәббәт дип уйлама син бу уенны!
Караңгыдан туеп инде таң да ата.
Көн туганчы бәйрәм итеп калыр өчен,
Теләк-Җанвар ярсып һаман читлек вата.

*1991*

## Иске радио

Чоланда иске радио.
Эче куыш, тузан баскан.
Яшерергә теләп аны
Үрмәкүч пәрәвез аскан.

Бер сүз дәшми... Ялгызлыктан,
Бәлки, акылын җуйгандыр.
Бәлки, күпме еллар буе
Ялган сөйләүдән туйгандыр.

*1989*

## Әби

Ачы еллар тозы утыргандыр, —
Шуңа шундый аның күзләре.
Битләрендә җыерчыклар түгел, —
Нужа камчысының эзләре.

## Язалар авыл турында...

Әй, шагыйрьләр, туган авылларны
Мактап, зурлап, сагынып язасыз да,
Китапләрдә ята мәдхияләр,
Тузан җыеп, аунап, яраксызга.

Сезнең кәгазьләрдә бакча булып,
Гөрләп чәчәк аткан туган яклар
Бик үзгәрде... Ә ул авылларга
Хәзер инде ясин чыгар чаклар.

Замананың кайнар сулышыннан
Коеларның суы күптән кипте;
Кое сиртмәләре торналар күк
Бер билгесез якка очып китте.

Ил басарга килгән гаскәр кебек —
Заводларның кара торбалары,
Яшел болыннарны каплап ята
Куе, сары агу-томаннары.

Гүя кайгылардан чәч коела, —
Сирәгәя урман бөдрәләре,
Юынтык су кебек булып калды
Елгалары, чишмә һәм күлләре.

Яза шагыйрь «авыл ямьле» диеп,
Шигъри чишмә авылларны данлый.
...Ә авылда җәйләр житкәч, абзый
Печән чабар урын таба алмый.

*1989*

## 1991 ел. Августның бер көне

*(Кара шигырь)*

Чыккан идем урамга мин, көн туды дип,
Автобуска утырырга хәл булмады.
Җәяү киттем, какырыкларны таптый-таптый,
Ботинкамның төбе купты... юл уңмады.

Кесәләргә тыккан идем кулларымны,
Элеккечә такыр икән кесәсе дә...
Буш кибеттә йөргән булам, нидер эзләп,
Апыйсы да килми юкса, эчәсе дә.

Тырамвайның тынчу, сасы салонында
Йотып барам ирексездән ыгы-зыгыны,
Ике татар сиптерәләр гел урысча.
...Ник шартламый бу тырамвай, авызыңны?!

Якты аваз сорап куйды күңелләрем,
Шул сәбәпле офыкларга уйлар ага.
Бу вакытта дер селкенә шәһре Казан —
Көнне ертып чиркәүләрнең чаңы кага.

Бер хатынга барган булдым, йокларга дип,
Өе җылы, китаплар бар киштәсендә.
Кырыемда гырлап ята хайван сыман,
Бер таракан чабып йөри җилкәсендә.

Чистартырга хәле җитми табигатьнең
Бу пычракны. Көчсез монда җәй яңгыры.
Сыраханәләрдән чыккан сидек исе
Нык куерта чаң авазын — шәп яңгырый.

Саф һаваны сагыныш, сусап йөргән чакта
Ишетәсе дә килми берни, күрәсе дә...
Өстәвенә лобырдата саруларны:
ГКЧП, Ельцин, ДПР, БТР...
Яшисем дә килми минем, үләсем дә.

*Август, 1991*

* * *

Өй янында гарип тал агачы,
Тыңлап арыгач кошлар авазын,
Кояш баю белән, пыш-пыш кына
Укыйдыр күк кичке намазын.

Ә таң аткач: җәен, кышын, язын
Җилләр иссә, тагын җанлана.
Әллә авыртудан шыгырдый ул,
Әллә тормышыннан зарлана.

## *Ала алмады*

Өелделәр автобусның ишегенә,
Купты тавыш, этеш, сүгенү,
Беркемнең дә юктыр уйларында
Бу һөҗүмдә артка чигенү.

Тик бер бабай тора читтән карап
(Медальләре яна ялтырап),
Авылына бүген кайтуына
Өметен өзеп, тәмам аптырап.

Менә йөри бабай вокзал буйлап,
Туктап тыңлый диктор авазын.
Арыган, талган. Хәтта, хәле бетеп,
Ботинкасы «ачкан авызын».

Үтте гомер, юк шул егет чаклар,
Элеккеге дәрман калмады.
Яуда шәһәрләрне алган кеше
Автобусны «ала» алмады.

* * *

Тере тәнгә пычак кадагандай,
Җир тетрәтеп субай кагалар,
Җан өшеткеч «прогресс» тавышыннан
Качып бетте хәтта каргалар.

Исерек ирдән поскан хатын сыман,
Читтәрәк бер авыл сагайган,
Урамында үскән каеннары
Көздән түгел, куркып саргайган.

Менә төйнәлер дә тимер йодрык
Кыйнап ташлар шушы авылны.
Чалышайган басу капкалары
Каршы алыр соңгы давылны.

Комсызлыктан ярсып, сукыраеп
Болгый «прогресс» үткен хәнҗәрен.
Оча алмый калган кош шикелле
Тора авыл, көтеп әҗәлен.

* * *

Һаман буран җирдә, һаман давыл...
Хәтта дөнья инде чайкала.
Мәңгелек дау игълан иткән төсле,
Өметләрдән тыны капкан килеш,
Безнең өнсез еллар чаң кага.

* * *

Ышанмыйм мин үлем барлыгына,
Җирем ачкач соңгы кочагын,
Чыдамам мин аның тарлыгына,
Мәңгелеккә чыгыш очармын.

Мин кайтырмын Җиргә, еллар узгач,
Бу заманның җырын җырларга.
Мәңгелеккә киту мөмкин, мөмкин! —
Рәхмәт укыйм үткән елларга.

Көчем бетсә, мин иңәрмен Җиргә —
Ял итәргә тормыш шавыннан.
Бу — хәл җыю булыр минем өчен,
Мәңгелеккә очар алдыннан.

Үлемсезлекләрнең тирән серен
Беләм сыман бары мин генә.
Риза түгел үлем барлыгына,
Мин дөньяга килдем мәңгегә!

## *Фахишә*

Исемең онытылган,
Гомерең сатылган,
Бер төнгә яралган
«Мәхәббәт» бөрчеге.
Иннеккә буялган,
Төкереп сытылган,
Сүнгән һәм саргайган
Тәмәке төпчеге.

## Аттылар ана этне

Җирдә мәрхәмәт барына
Өзәрсең дә өметне:
Этләр өере җыя дип,
Аттылар ана этне.

Үтерделәр җан иясен,
Ана булмасын өчен.
Аттылар... китеп бардылар,
Канатып кышның кичен.

Елады җил, ята-ята
Канлы карның өстенә.
Йолдызлар чыкмады куркып, —
Күктә кара төс кенә.

Очты җаны бичараның,
Кермәде ул ояга —
Очты төннең үзәгенә,
Үпкәләп бу дөньяга...

* * *

Аерылышу газаплары
Төн йокысы бирмиләр,
Күзгә җилләр тәрәзәмне
Дер селкетеп тиргиләр.

Тәрәзәмне киереп ачып,
Каршы әйтердәй булам.
...Дөнья давылын күмәр күк
Минем җандагы буран.

## *1937*

Сагайды йорт...
Авыр тынлык...
Шәүлә урам чатында.
Бу тирәдә нидер йөри,
Кемдер бар өй артында.
Үлем килеп керде өйгә,
Эт өрүдән туктагач...
Тора... киеме бик таныш:
Галифе һәм күн плащ.

## Октябрь азагы

Тәмамланды бөек симфония
Туган якның урман-кырларында.

Сихерләнгән сыман басып торам —
Соңгы аккорд алды көз-маэстро
Табигатьнең алтын кылларында.

* * *

Сабыйны юаткан кебек
Кочаклаган шәһәрне төн,
Йокы татлы булсын өчен
Сөйли серле әкиятен.

Һава тулы уенчыклар —
Саф алтыннан гына койган,
Уянса еламасын дип,
Хәтта Ай да элеп куйган.

Шәһәр йоклый...
Төн югалгач
Йолдызлыклар арасына,
Таң килер — якты, бәхетле, —
Әкият ахыры сыман.

*1989*

* * *

Күбрәк сана, кәккүк, күбрәк сана,
Санга санап санар саннарны,
Гомер дисбесенең төймәләрен —
Икәү бергә узар елларны.

Күп санама, кәккүк, күп санама
Башка төшәр хәсрәт саннарың;
Өметләрем инде бер өзелсә,
Сине бүтән тыңлый алмамын.

Саный кәккүк үзе белгән көйгә
Айлы төнне, алсу таңнарны;
Ә йөрәкләр үз көенә тибә
Санламыйча сансыз саннарны.

* * *

Нигә болай шомлы икән көннәр?
Нидер көткән сыман — тын һава.
Киткәненә бары ике атна,
Ә урамда инде кар ява.

Хәзер инде мин — Вакытның колы,
Менә тагын төнгә көн ава.
Бергә йөргән җәйге сукмакларга
Көне-төне ишеп кар ява.

Адашмасаң иде кышкы юлда,
Бу сагышка, ахры, юк дәва.
Тәрәзәләр өмет белән карый,
Ә дөньяга инде кар ява.

# Җырлар



## Нәрсә булды сиңа бүген?..

Нәрсә булды сиңа бүген,
Бүлмәмдәге нәни кошым?
Бу дөньядан туйдың мәллә,
Сайрый-сайрый җаен-кышын?..
Һәй, ни булды сиңа бүген?

Әллә синең авазыңны
Дөнья шавы күмә микән,
Моңнарыңның яктылыгын
Әллә беркем күрми микән?..
Һәй, ни булды сиңа бүген?

Кушымта:

Күңелләрең кая тарта,
очар кыйблаң кай тарафта,
Сине кайда кемнәр генә
кабул кылыр икән?
Оча күрмә, ташлап китмә,
инде мине ятим итмә.
Әллә соң син үзәгемнең
өзелгән бер кылы микән?

Нәрсә булды сиңа бүген,
Читлектәге зарлы җырым?
Бу бит синең дөньяң түгел,
Җирдә түгел синең юлың.
Һәй, ни булды сиңа бүген?

Хушлашырга иртә әле,
Җырлар көннәр алда әле,
Син бит Моңның җырчы колы!

Әйдә, җаным, җырла әле.
Һәй, ни булды сиңа бүген?

Кушымта:

Күңелләрең кая тарта,
очар кыйблаң кай тарафта,
Сине кайда кемнәр генә
кабул кылыр икән?
Оча күрмә, ташлап китмә,
инде мине ятим итмә.
Әллә соң син үзәгемнең
өзелгән бер кылы микән?

*1991–1992*

## Татар иле

Тагын ярсу хөкем сөрә күңелләрдә,
Идел өстен тибрәлдерә кыйбла җиле.
Әллә йөрәк, әллә өмет
Сулкылдыйдыр күкрәгемдә,
Уятырга ният итеп Татар илен.

Саклап килдек гасырлардан гасырларга
Бәгырьләрдә чәчәк аткан өмет гөлен,
Ул чәчәкләр ташны тишеп
Шытып чыга дастаннарда,
Мин ышанам, калкып чыгар Татар иле.

Табынам мин бүген һаман синең рухка,
Безнең көннәр ташу кебек шаулап килер.
Үткәннәрне генә түгел,
Киләчәгеңне сагынам,
Сагынам сине, бөек Татар иле!

*1995*

## Газиз халкым

Ачы язмыш йөген сөйри бер мосафир,
Әйтче миңа Җирдә яшәү хакын.
Мең кат сорыйм,
        һаман әле җавап ишетелми,
Нәрсә булды сиңа, газиз халкым?

Вәхши дөнья, кансыз аның кануннары,
Бу дөньяда үз юлында һәркем хаклы.
Тик шулай да
        җан ачысы белән синнән сорыйм:
Ничек сиңа ярдәм итим, газиз халкым?

Барыр юлың кай тарафка — кемнәр әйтер?..
Үзәгеңдә бармы әле янар ялкын?
Бүген миңа
        сулыш кебек тавышыңны ишетү кирәк,
Дөньяга бер аваз бирче, газиз халкым.

*1995*

## Сине югалтсам...

Төнгә кереп барабызмы,
Нигә болай караңгы?
Әллә томан арабызда,
Әллә авыр карадың...

К у ш ы м т а:

Миннән китте, синдә йөри
Күңелемнең яртысы,
Сине югалткан көнне үк
Мин үләрмен, ахрысы.

Сәгать саен күз алдымда.
Белмим, нигә юксынам,
Мондый тирән сагыш өчен
Хәсрәтем дә юк сыман.

К у ш ы м т а:

Миннән китте, синдә йөри
Күңелемнең яртысы,
Сине югалткан көнне үк
Мин үләрмен, ахрысы.

Мизгел саен яңа дулкын,
Мизгел саен сагынам,
Ни булгандыр зиһенемә —
Бары сиңа табынам.

К у ш ы м т а:

Миннән китте, синдә йөри
Күңелемнең яртысы,
Сине югалткан көнне үк
Мин үләрмен, ахрысы.

*2000–2001*

## Төнге сәяхәт

Төн ябынгач йолдызлы юрганын,
Дәшә мине Шигырь-Төнгизәр.
Көмеш сулы яп-якты елгада
Бер кечкенә салда мин йөзәм.

К у ш ы м т а:

Ике яктан кычкыралар миңа
Яңгыратып ярлар арасын.
Сал чайкала, йөзә бата-калка,
Ләкин килми ярга борасым.

Җырларымнан үрелгән салыма
Дулкыннар да — уен-шаяру,
Җирдәгеләр тора аптырап —
Уемда юк җиргә таяну...

К у ш ы м т а:

Ике яктан кычкыралар миңа
Яңгыратып ярлар арасын.
Сал чайкала, йөзә бата-калка,
Ләкин килми ярга борасым.

Тик һәрвакыт таң атарга ашыга,
Гүя мине Кояш сагына,
Көн шатланып суза кулларын
Минем нәни, кыю салыма.

К у ш ы м т а:

Ике яктан кычкыралар миңа
Яңгыратып ярлар арасын.

Сал чайкала, йөзә бата-калка,
Ләкин килми ярга борасым.

Төн ябынгач йолдызлы юрганын,
Дәшә мине Хыял-Төнгизәр,
Көмеш сулы яп-якты елгада
Бер кечкенә салда мин йөзәм.

К у ш ы м т а:

Ике яктан кычкыралар миңа
Яңгыратып ярлар арасын.
Сал чайкала, йөзә бата-калка,
Ләкин килми ярга борасым.

*1989*

## Тәүбә

Бу кайгылы хәлдә
Таң атамы әллә?..
Тагын өмет биреп ява кар.
Китмә, китмә, китмә,
        хушлашырга иртә,
Минем сиңа әйтер сүзем бар.

Нигә кирәк сүзләр?..
Нигә һаман күзләр
Өмет белән күккә багалар?
Сукма, сукма, язмыш,
        үтерерсең ялгыш,
Минем әле җырлар зарым бар.

Дөнья чиксез булса,
Вакыт һаман узса,
Нигә миңа бүген дөнья тар?!
Күккә әйттем фөрьяд:
        кичерерсең, Ходай —
Минем сиңа бирер җаным бар.

Бу кайгылы хәлдә
Таң атамы әллә?..
Һаман өмет биреп ява кар.
Китмә, китмә, китмә,
        хушлашырга иртә,
Минем сиңа әйтер сүзем бар.

*1997*

## *Син эзләмә мине...*

Син эзләмә мине шаулы урамнарда...
Мин килеп чыгармын көзге томаннардан.
Син эзләмә мине, күзләп язлар ягын...
Мин — бу табигатьнең кышка атлаган чагы.

Син эзләмә мине ачы бураннарда...
Мин чәчәк атармын җәйге болыннарда.
Син эзләмә миндә төсләрнең гел агын...
Мин — бу табигатьнең гөлгә күмелгән чагы.

К у ш ы м т а:

Аяз көндә зәңгәр күкне ярып
Яшен сукса, бу — минем нәфрәтем.
Тик шулай да кайтып һаман мин Җиргә тезләнәм.
Минем юлым — якты йолдызның нуры,
Бу хәяткә күп минем рәхмәтем.
Тик шулай да мине син Җирдә, син Җирдә эзләмә!

Син эзләмә мине төнге күккә карап,
Табалмассың җавап, йолдызларны санап.
Син эзләмә мине! Нәрсә әйтим тагын?..
Мин — күктәге Айның күренми торган ягы.

К у ш ы м т а:

Аяз көндә зәңгәр күкне ярып
Яшен сукса, бу — минем нәфрәтем.
Тик шулай да кайтып һаман мин Җиргә тезләнәм.
Минем юлым — якты йолдызның нуры,
Бу хәяткә күп минем рәхмәтем.
Тик шулай да мине син Җирдә, син Җирдә эзләмә!

*1989–1990*

## Казан-кала

Ник болай караңгы бу көн?
Күңелдә гарасат бүген.
Син минсез яши алырсың,
Мин синсез яши алмам.
Шуны белгәнгәдер инде,
Өметләнеп, синңа сеңдем,
Кай тарафтан ярдәм көтик,
И гүзәл Казан-кала?!

Тетрәтеп Татар ил-көнен,
Караңгылап якты күген,
Боектырып Кабан күлен
Чиркәүнең чаңы кага.
Нәфрәтемне көчкә тыям,
Үз-үземә әле дә сыям,
Син моңа ничек түзәсең,
И горур Казан-кала?!

Җырлый бөек халык-әдип:
«Узган гомер — аккан су», — дип...
Кыйблаларга таба ага
Мәңгелек Идел-елга.
Тоткынлыкта мин калмамын,
Тик синсез яши алмамын,
Агышлар китикме әллә,
И бөек Казан-кала?!

Ник болай караңгы бу көн?
Күңелдә гарасат бүген.
Син минсез яши алырсың,
Мин синсез яши алмам.

Шуны белгәнгәдер инде
Өметләнеп, сиңа сеңдем,
Кай тарафтан ярдәм көтик,
И гүзәл Казан-кала?!

*2000–2001*

## Сентябрь алмалары

Яшьлегемне эзләп чыктым
Җәйнең болыннарына,
Әйтте җил: «Синең яшьлегең
Февраль бураннарында».

К у ш ы м т а:
Гел бураннарда эзләдем
Язның тал-тирәкләрен,
Сентябрьнең алмаларын,
Июньнең җиләкләрен.

Дөрес чамаламаганмын
Гомеремнең чикләрен,
Авыз итә алмый калдым
Июньнең җиләкләрен.

К у ш ы м т а:
Гел бураннарда эзләдем
Язның тал-тирәкләрен,
Сентябрьнең алмаларын,
Июньнең җиләкләрен.

Ник болай тиз үтә көннәр?
Һаман да аңламадым.
Бакчамда җиргә коела
Сентябрь алмалары.

К у ш ы м т а:
Гел бураннарда эзләдем
Язның тал-тирәкләрен,
Сентябрьнең алмаларын,
Июньнең җиләкләрен.

Алмагачым әйтте миңа:
«Югаласы югалган,
Озак йөргәнсең февральдә,
Шуңа чәчең агарган».

К у ш ы м т а:

Гел бураннарда эзләдем
Язның тал-тирәкләрен,
Сентябрьнең алмаларын,
Июньнең җиләкләрен.

Йөгердем кыш уртасына —
Яшьлекне табыйм инде.
Адаштым, хәлем җитмәде,
Ярый әле яз килде.

К у ш ы м т а:

Гел бураннарда эзләдем,
Язның тал-тирәкләрен,
Сентябрьнең алмаларын,
Июньнең җиләкләрен.

Җирдә бәйрәм. Ничәнче кат
Чәчәк ата сиреньнәр.
Иң кирәк сүзне әйтерләр
Инде башка иреннәр.

К у ш ы м т а:

Язда булдым, җәйне гиздем
Яратып һәм табынып.
...Йөрим алма бакчасында,
Бураннарны сагынып.

*2001*

## Галия

Болында җәй инде, тагын сагыш килде,
Син киткән тарафтан күзем алмыйм инде,
Шул яктан назлы җил сәламнәр китерде:
Мин сине сагынам!

Кил инде, кил, мин көтәм зарыгып,
Син киткән офыкка табынам.
Яңгырый татлы моң урманнар артыннан:
Мин сине сагынам!

К у ш ы м т а:

Син торган яклардан җылы җилләр иссә,
Сөенеп чәчәкләр баш ия,
Җәй сине юксына, кошлар да җырлыйлар:
Галия, Галия, Галия!

Хыялым яп-якты язмышым күгендә,
Кавышу өмете дәрт бирә күңелгә,
Болыннарда сине эзлимен бүген дә —
Мин сине сагынам!

Кил инде, кил, мин көтәм зарыгып,
Син киткән офыкка табынам.
Яңгырый татлы моң урманнар артыннан:
Мин сине сагынам!

К у ш ы м т а:

Син торган яклардан җылы җилләр иссә,
Сөенеп чәчәкләр баш ия,
Җәй сине юксына, кошлар да җырлыйлар:
Галия, Галия, Галия!

*1993*

## Чыктым юлга

Кай тарафтан исте җилләр —
Сизми калдым, килде хәбәр,
Еракларга мине дәшә
Хыял кебек якты сәфәр,
Якты сәфәр.

Җиңел түгел минем юлым,
Кышлар була, яңгыр ява,
Тик галәмдә, өмет булып,
Миңа да бер йолдыз яна,
Йолдыз яна.

Бирде Җиһан миңа Яшәү җырын,
Гомерем буе аны җырлармын,
Бирче, Язмыш, миңа озын гомер —
Мин Дөньяны тыңлап туймамын.

*1989*

## Апрельдә кар ява

Нинди сагыш соң бу килә көн дә?
Булса иде шуңа бер дәва.
Арабызны тагы да салкынайтып,
Апрель азагында кар ява.

К у ш ы м т а:

Ява карлар, ява карлар эзләреңә синең,
Бураннарга керәм ялгызым.
Нишләргә соң, әйтче миңа, әгәр синсез килсә
Шулай салкын булып һәр язым?!

Табигатьнең булмый хаталары,
Тик тормышта туа хаталар.
Һаман ява карлар яз булса да,
Эзләреңне күмеп ява кар.

К у ш ы м т а:

Ява карлар, ява карлар эзләреңә синең,
Бураннарга керәм ялгызым.
Нишләргә соң, әйтче миңа, әгәр синсез килсә
Шулай салкын булып һәр язым?!

*1988*

## Газап

Бу Галәмдә тузан бөртеге мин, шуны беләм.
Шуңа, ахры, мең кат яшим, мең кат үләм.
Бер халәттә яшәргә мин күптән сусыйм,
Ник, Хәсрәтем, галәмнәрдин зуррак соң син?!

Төннәр белән сөйләшкәндә җан авазым,
Тоям сыкрап бу дөньяның һәр газабын.
Гүя кемдер алып көчле кулларына,
Авырттырып чиртә күңел кылларымны.

Ага еллар, ага сулар, ага моңнар,
Бәлки, бу моң берәр кайчан тәмам тынар.
Әй тәкъдирем, яшәвемдә булса мәгънә,
Газабымны тәмамларга бирче вәгъдә.

*1991*

## Изге җир

Пәйда булса күктә кара болыт,
Яшен сукса өмет-хыялымны,
Туган яктан килер якты аваз,
Томаннардан арындырыр юлны.

Туган ягым — мәңге кояш,
Йөрәк кыса сагынудан,
Туган якта яшел урман
Көн дә иртән әйтә азан.

К у ш ы м т а:

Анда әле яши иман,
Изгелеккә инану бар,
Анда җанны чистартырдай
Матурлыкка соклану бар.

Анда кичен, дөнья тынгач,
Намаз укый бөдрә таллар,
Анда сиңа Яшәү биргән
Мәңгелеккә табыну бар.

Изге җирдән күз күрмәгән җепләр
Сузылганнар миңа еллар буйлап.
Язлар җиткәч, мине сагынудан
Каеннары юлга чыга елап.

Туган яктан хәбәр килсә,
Шунда карап син җырың әйт,
Туган якның һәр авазы —
Үзе үлмәс бер мөнәҗәт.

К у ш ы м т а:

Анда әле яшь иман,
Изгелеккә инану бар,
Анда җанны чистартырдай
Матурлыкка соклану бар.

Анда кичен, дөнья тынгач,
Намаз укый бөдрә таллар,
Анда сиңа Яшәү биргән
Мәңгелеккә табыну бар.

*1990*

## Ярым ай

Төнге күктә берДәнбер ярым ай,
Түгелә Җиргә сары сагышы,
Ишетелә авыр тынлык аша
Кемнәрнеңдер рәнжү тавышы.

Төнге күктә берДәнбер ярым ай,
Җирне яктыртырга телиме,
Күпме еллар кара бушлык аша
Мәчетләрне эзләп йөриме?

Кушымта:

Яктылыгың ага мәңгелеккә таба,
Синең юлың изге — син күкләрдә һаман.
Ваталмады сине заман вәхшилеге,
Сүндермәде сине кара заман.

Төнге күктә берДәнбер ярым ай,
Озата килә чорлар агышын.
Җимерелгән манаралар эзләп,
Мәңге кояр Җиргә сагышын.

Кушымта:

Яктылыгың ага мәңгелеккә таба,
Синең юлың изге — син күкләрдә һаман.
Ваталмады сине заман вәхшилеге,
Сүндермәде сине кара заман.

*1989*

## *Каргама*

Елама,
Аерылабыз диеп син елама,
Тагын сыный безне язмышлар.
Каргама,
Беркемне дә, зинһар, син каргама,
Бәхет алып килми каргышлар.

К уш ы м т а:

Күрәсеңме, күзге күктән берөзлексез яңгыр ява,
Елама, елама.
Әйтерсең лә безнең өчен гөнаһларны кемдер юа,
Каргама, каргама.
Сау бул!

Елама,
Югалтуга дәва юк дөньяда.
Кемнәр җиңәр икән бу зарны?
Каргама,
Таң атканда, офыкка кара да —
Син аңларсың: барыбызга бер Җир шары.

К у ш ы м т а:

Болай да бит күзге күктән берөзлексез яңгыр ява,
Елама, елама.
Әйтерсең лә безнең өчен гөнаһларны кемдер юа,
Каргама, каргама.
Сау бул!

*1994*

## Мосафирга эндәшү

Заманалар зинданыннан качып,
Күк йөзендә сүнмәс Ай балкыды.
Билләреңдә үткен хәнҗәр иде,
Йөрәгеңдә — изге Дин ялкыны.

Син илләрне яулап ала идең,
Диңгезләр дә сиңа сай иде.
Аллалары алышынган чакта,
Күгеңдә бит шул бер Ай иде.

Әй, мосафир, йолдызларга карап,
Мәңгелеккә юл тотуың, ахры.
Нишләп синең атың аксап бара,
Үзең бөкре, җырың бик акрын?

Заманалар тозагыннан качып,
Мәңгелек сәфәргә чыкты юлчы.
Уңайга ис, зинһар, кыйбла җиле,
Әй, изге Ай, аңа юлдаш булчы!

Хыялларың, беләм, уклар кебек,
Офыкларга таба шаулап ява.
Мин бит күрәм: йөрәгеңдә синең
Өмет уты әле һаман яна.

*1989–1990*

## Хәерле юл!

Юлларыңа ап-ак җәймә, хәерле юл!
Бу дөньяда юллар авыр, түземле бул.
Керфегеңә төшеп кунган
ак кар бөртекләренең
Күз яшенә әверелгән мизгеле бу.

Юлларыңа ап-ак җәймә, хәерле юл!
Инде кабат сине миңа китермәс ул.
Тау артында, котылгысыз
янып калган шәфәкъ булып,
Мәхәббәтнең тып-тын гына сүнүе бу.

Юлларыңа ап-ак җәймә, хәерле юл!
Офыклардан офыкларга сузылган ул.
Икебезгә язмыш биргән
бәхет атлы бер мизгелнең
Мәңгелектән Мәңгелеккә китүе бу.

*1997*

## Җырларым-хыялларым

Кояшлы, чәчәкле бу якты дөньяга
Кошлар күк җырларга килдем мин.
Офыклар артына, җилләргә ияреп,
Җыр булып очарга телим мин.

Дәртләнә йөрәгем, ашкына күңелем,
Еракка мәңгелек моң ага.
Кайгырам, шатланам, иң олы бәхетем —
Килүем бу җырлы дөньяга.

Кушымта:

Җырларым кабатланыр минем,
Үтсеннәр елларым,
Җырларым — канатларым минем,
Җырларым — хыялларым.

Урманнар, болыннар, чишмәләр, елгалар
Җырыма кушылып җырлыйлар.
Тын кала галәмнәр сихерле төннәрдә —
Йолдызлар йотлыгып тыңлыйлар.

Кушымта:

Җырларым кабатланыр минем,
Үтсеннәр елларым,
Җырларым — канатларым минем,
Җырларым — хыялларым.

*1988*

## Язгы яңгыр

Дәшмә бер сүз миңа,
Тынлык кирәк җанга,
Буш сүзләрдән арынуы бигрәк авыр.
Күрәсеңме, бүген
Май аеның күген —
Дәва булып Җиргә ява язгы яңгыр.

Ач тәрәзәләрне,
Йолкы пәрдәләрне,
Күңел ничәнче кат язларга алданыр.
Яңа гөлләр өчен,
Куеп бөтен көчен,
Тагын Җиргә ява Күктән язгы яңгыр.

Гомер үтеп китәр,
Яңа язлар җитәр,
Безнең җырлар еллар аша әле яңгырар.
Ярып зәңгәр күкне,
Кичеп Мәңгелекне
Җиргә явар назлы язгы яңгыр.

Дәшмә бер сүз миңа,
Тынлык кирәк җанга,
Буш сүзләрдән арынуы бигрәк авыр.
Күрәсеңме, бүген
Май аеның күген —
Дәва булып Җиргә ява язгы яңгыр.

## Кар яуганда

Ап-ак карлар ява, дөнья ак төс ала,
Тәрәзәдән карап елмая кыз бала.
Алда якты хәят, иңнәрдә ак канат,
Хыял диңгезендә таш кала чайкала.

К у ш ы м т а:

Елмая, елмая, елмая,
Гомерләр офыкка юл ала,
Мәңгелек пакьлек дип ышана...
Тәрәзә янында кыз бала.
Елмая, елмая, елмая,
Ак бәхет, ак дөнья, ак кала,
Илаһи сафлыктан таң калган
Тәрәзә янында кыз бала.

Ап-ак карлар ява, дөнья тының калган,
Тәрәзәдән карап елама кыз бала.
Бәхетнең гомере — карларның эрүе...
Ташулар ерак дип барсы да алдана.

К у ш ы м т а:

Елама, елама, елама,
Бураннар офыкка юл ала,
Карларның сафлыгын кызгана
Тәрәзә янында кыз бала.
Елама, елама, елама,
Тикмәгә түгелдер — кар ява.
Әйтерсең, ак өмет бар карда —
Тәрәзә янында кыз бала.

*1996–1997*

## Юлларда бозлавык

Бозлавык юлымда, язмышым кулымда,
Бикләдем мин салкын өемне.
Давылдан да зәһәр, буранласа әгәр,
Башымдагы уйлар өере.

К у ш ы м т а:

Мин чабам еракка, яктырак тарафка,
Ник болай тайгак соң бу юллар?
Исән-сау җиталсам, кем көлеп каршылар,
Артымда сагынып кем елар?

Яшәүнең мәгънәсен беркайчан белмәссең.
Мин аңа көн саен тартылам.
Яңасын ачаммы, үземнән качаммы —
Абынам да кабат талпынам.

К у ш ы м т а:

Мин чабам еракка, яктырак тарафка,
Ник болай тайгак соң бу юллар?
Исән-сау җиталсам, кем көлеп каршылар,
Артымда сагынып кем елар?

Караңгы көннәрдән, качкандай җеннәрдән,
Мин чабам еллардан елларга.
Уйлыймдыр, янәсе, яшәүнең мәгънәсе —
Үтү дип бу тайгак юллардан.

К у ш ы м т а:

Мин чабам еракка, яктырак тарафка,
Ник болай тайгак соң бу юллар?

Исән-сау җиталсам, кем көлеп каршылар,
Артымда сагынып кем елар?

Бозлавык юлымда, язмышым кулымда,
Бикләдем мин салкын өемне.
Давылдан да зәһәр, буранласа әгәр,
Башымдагы уйлар өере.

К у ш ы м т а:

Мин чабам еракка, яктырак тарафка,
Ник болай тайгак соң бу юллар?
Исән-сау җиталсам, кем көлеп каршылар,
Артымда сагынып кем елар?

*2001*

## *Кайда син?..*

Кайда син, кая югалдың,
Кай тарафларга юл алдың,
Һәр таңны сиңа юрадым,
Кайда син?
Сагышлы җырлар җырлыймын,
Кемнедер сагыныш елыймын,
Кайларга җырым юллыйм мин,
Кайда син?

К у ш ы м т а:

Агыла еллар, агыла,
Сагынам сине, сагынам,
Хәсрәтем әрни тын гына,
Син кайда?
Гомерем буе сине эзләрмен,
Ничекләр моңа түзәрмен,
Син кайда, син кайда,
Син кайда?

Төшемдәме, өнемдәме,
Төнемдәме, көнемдәме,
Югалды дөньяның яме,
Кайда син?
Бәлки, син дөньяда юктыр,
Хыяллар кабызган уттыр...
Күгемне бер мәлгә яктырт!
Бармы син?.. Бармы син?..

К у ш ы м т а:

Агыла еллар, агыла,
Сагынам сине, сагынам,

Хәсрәтем әрни тын гына,
Син кайда?
Гомерем буе сине эзләрмен,
Ничекләр моңа түзәрмен,
Син кайда, син кайда,
Син кайда?..

*1994*

## Азатлык

Һәй, тагын кемнәр анда,
Халкымны минем алдап,
Вәгъдә итә мәңгелек шатлык?!
Ышанма син аларга —
Аумакай агайларга —
Сиңа кирәк бүген азатлык!

К у ш ы м т а:

Әй, әһә-һәй, азатлык!
Әй, әһә-һәй, азатлык!

Һәй, тырыш талпынырга,
Үзеңә ышанырга,
Дөньяда бар изге бер хаклык,
Коллык зинданын ватып,
Чыгарга куша вакыт,
Ул хаклыкның аты — Азатлык!

К у ш ы м т а:

Әй, әһә-һәй, азатлык!
Әй, әһә-һәй, азатлык!

Һәй, кабат син алданма
Җирдәге «аллаларга»,
Чиге булсын инде газапның.
Сызылып якты таң атар,
Уянырсың син, татар,
Киләчәктән дәшә азатлык.

К у ш ы м т а:

Әй, әһә-һәй, азатлык!
Әй, әһә-һәй, азатлык!

*1995*

## Көзге яфрак

Калтырана сары яфрак,
Кил инде якынырак,
Тып-тын гына тор янәшә,
Дәшмә бер сүз миңа, дәшмә.
Ник боектың әле син дә,
Туңдың мәллә көзге җилдә?
Кайгы бар бу мизгелдә —
Сары яфрак төшә җиргә.

Калтырана сары яфрак,
Синнән миңа ара ерак,
Әйткән сүзләр берни түгел.
Шуңа, ахры, әрни күңел.
Ник битараф бу яшәеш?
Нинди аяныч күренеш!
Кайгы килде мәллә илгә —
Сары яфрак төшә җиргә.

Калтырана сары яфрак,
Көтә аны юеш туфрак,
Нигә болай якын ара? —
Сары яфрак төшеп бара.
Бик боекма әле син дә,
Күшексәң дә көзге җилдә.
Бу — мин яшәү мизгелендә
Яфрак булып төшәм җиргә.

Бик боекма әле син дә,
Күшексәң дә көзге җилдә.
Үзем яшәү мизгелендә
Яфрак булып төшәм җиргә.

*2000–2001*

## Сафлык

Саф чишмәдән су алды кыз бала,
Көн таң калды, җанланды табигать.
Мин хыяллар эчендә адаштым,
Бу — могҗиза, бу — сихри сәяхәт.

Саф чишмәдән су алды кыз бала,
Бу сафлыкка куанды бар Җиһан.
Пакь йөзендә — оялчан елмаю,
Ул таңнарның назларын җыйган.

К у ш ы м т а:

Кал, чибәр кыз, хәтердә гомергә,
Бу мизгел бер генә, бер генә.
Кал син, Сафлык, кабатлан көн саен
Чишмә булып мәңгегә.

Саф чишмәдән су алды кыз бала, —
Ямь өстәде чәчәкле җәйләргә.
Шул мизгелләр дәрт бирә, ахрысы, —
Җир Галәмдә һаман да әйләнә.

К у ш ы м т а:

Кал, чибәр кыз, хәтердә гомергә,
Бу мизгел бер генә, бер генә.
Кал син, Сафлык, кабатлан көн саен
Чишмә булып мәңгегә.

*1989*

## Чулман буйларына ятты томан...

Чулман буйларына ятты куе томан
Михнәтләрдән саклар өчен иңгән сыман.
Тәкъдир язган яман — яктылык юк һаман,
Ул томаннар безне саклый алмый имди.

Чурагайлар Чулман елгасында йөзә,
Борыны белән зәһәр агымсуны сөзә.
Сулар белән еллар ага, әле дә түзәм
Кайгы-хәсрәт дәрьясында йөзеп имди.

Идел белән Нократ арасында ага
Чулман-елга изге кыйблаларга таба,
Бәргәләнә бер чурагай чыгыш ярга, —
Охшаган ул йөрәгемә минем имди.

Чулман буйларына ятты куе томан
Михнәтләрдән саклар өчен иңгән сыман.
Тәкъдир язган яман — яктылык юк һаман,
Ул томаннар безне саклый алмый имди.

*1996*

## Татарлар килә

Нинди кәрван килә шәрыктан?
Бу тарафта нәрсә югалткан?
Нинди сөрән дәшә еракtan?
Күк һәм Җир тоташкан офыктан.

К у ш ы м т а:

Һә-ә-ә-әй, татарлар килә,
Һә-ә-ә-әй, татарлар килә. *(4 тапкыр.)*

Артта калды яман гасырлар,
Калкытса да язмыш чатырлар,
Ай яктырткач, юлны табарлар —
Тарих буйлап килә татарлар.

К у ш ы м т а:

Һә-ә-ә-әй, татарлар килә,
Һә-ә-ә-әй, татарлар килә. *(4 тапкыр.)*

Бик күп гаеп-хата киткәндер...
Безне тарих гафу иткәндер.
Бу олы юл безне илтәдер
Мәңгелектән Мәңгелеккәдер.

К у ш ы м т а:

Һә-ә-ә-әй, татарлар килә,
Һә-ә-ә-әй, татарлар килә. *(4 тапкыр.)*

*1995*

## Янымда син юк икән

Кар яуды бүген иртән,
Ишегалдын пакь иткән.
Син киткәч кенә күрдем мин —
Алъяшкычың ак икән.

К у ш ы м т а:

Алъяшкычың ак икән —
Абайладым мин иртән,
Күңел акка куанса да,
Янымда син юк икән.

Төшкә керәсең, иркәм,
Ниләргә юрыйм икән,
Ак яулыгыңны йомарлап
Утырыш җырлыйм микән?

К у ш ы м т а:

Яулыкларың ак икән —
Үзем күрдем мин иртән,
Акка карап юансам да,
Янымда син юк икән.

Бетте көннең яктысы,
Әрни йөрәк ярасы,
Өстәлдәге ак кәгазьгә
Белмим, ниләр язасы...

К у ш ы м т а:

Кар яуды бүген иртән,
Дөньяларын ак иткән,
Киемнәрең генә түгел,
Син үзең дә пакь икән.

*2001–2002*

## Яшенле яңгыр

Кинәт күк күкрәде, яшене яшьнәде,
Урталай ярылды башкала.
Кешеләр ашыга яңгырдан качарга,
Һәммәсе йөгерә, ашкына.

К у ш ы м т а:

Чабыша кешеләр,
Әй мөшкел соң эшләр,
Йөгерә карты да, яше дә.
Күк, күкрә катырак,
Кешене калтырат,
Курыксыннар күктәге яшеннән.

И курка шулкадәр яшеннән бу шәһәр,
Кой, әйдә, яңгырым, дөньяга,
Аз гына булса да чистарсын барысы да,
Гөрләвек әйләнсен дәрьяга.

К у ш ы м т а:

Чабыша кешеләр,
Әй мөшкел соң эшләр,
Йөгерә карты да, яше дә.
Күк, күкрә катырак,
Кешене калтырат,
Курыксыннар күктәге яшеннән.

Яшеннәр ялтырар, яңгырлар гел явар,
Күкләрнең авазы яңгырар.
Һәр кеше курыксын, аз гына уйлансын,
Еш яусын яшенле яңгырлар.

К у ш ы м т а:

Чабыша кешеләр,
Әй мөшкел соң эшләр,
Йөгерә карты да, яше дә.
Күк, күкрә катырак,
Кешене калтырат,
Курыксыннар күктәге яшеннән.

Кинәт күк күкрәде, яшене яшьнәде,
Урталай ярылды башкала.
Кешеләр ашыга яңгырдан качарга,
Һәммәсе йөгерә, ашкына.

К у ш ы м т а:

Чабыша кешеләр,
Әй мөшкел соң эшләр,
Йөгерә карты да, яше дә.
Күк, күкрә катырак,
Кешене калтырат,
Курыксыннар күктәге яшеннән.

*2001*

## Ашыкма

Ашыкма син! Ерагайма!
Үткәннәрнең моңын кем тыңлар?!
Балачагың гөрләп узган
инеш буйларында
Зарыгып көтә сине, сагынып, бөдрә таллар.

Ашыкма син! Тайгак юллар...
Хәл алырга ирек бирми алар.
Мең шифалы сулыш белән
сине дәваларга
Офыкларга карап көтә бөдрә таллар.

Ашыкма син ваз кичәргә, —
Өмет булып сызылып ата таңнар.
Заманаың давылында
хакың юк үлергә,
Сине сагынып көтә анда бөдрә таллар.

Онытма син — гомер кыска!
Кошлар булып күктә оча еллар.
Гөнаһларың күптер диеп,
синең өчен һаман
Су буенда дога кыла бөдрә таллар.

Ашыкма син! Ерагайма!
Үткәннәрнең моңын кем җырлар?!
Балачагың гөрләп узган
инеш буйларында
Зарыгып көтә сине, сагынып, бөдрә таллар.

*1996*

## Сызыклар

Кайгы-хәсрәт йөрсә дә янәшә,
Җирдә яшәвемдә кызык бар.
Әле монда, әле анда чагыла
Кемдер сызган серле сызыклар.

Югалмабыз кебек талпынабыз,
Кузгалабыз өйдән пыр-тузып,
Туган җирдән гел аермак була
Дошман сызган кара бер сызык.

Еракларда кара ташлар күрдек,
Уклар очты шунда сызгырып.
Дошман чирүе дип белгән идек,
Алда исә — офык сызыгы.

Вакыт та бит бер сызыктан бара,
Гомер үзе китәр узышлар.
Хәсрәт камчысының эзләредер
Маңгайдагы буй-буй сызыклар.

Дөнья чиксез булып тоела да
Хыял нуры оча сузылып.
...Яшәү белән үлем арасында
Кылыч чапкан канлы бер сызык.

Адымнарың чамалап бас җиргә —
Кемдер кора яңа тозаклар,
Туганын да хәтта дошман итә
Шайтан сызган кыек сызыклар.

Нәрсә эзләп чабам дөнья буйлап,
Нигә һаман өмет офыкта?

Яшәгәндә кемнәр төгәл әйтер
Тукталасын кайсы сызыкта.

Вәхши дөнья кыйный кызганмыйча,
Тик шулай да Җирдә кызык бар, —
Мәңгелеккә елга булып аккан
Яшәү дигән сәер сызык бар.

*1998–1999*

## Беләзек

Галәмнең иркендә, күкнең бер читендә
Сәфәрен тәмамлап Ай бата.
Мин калдым югалып, бер мәлгә таң калып —
Дөньяда янә бер таң ата.

Кушымта:
Йортның һәр тарафын, өйнең һәр почмагын
Яктырта синең нурлы йөзең,
Йа Раббым, шулкадәр килешә үзеңә
Кулыңдагы беләзегең.

Каяндыр ерактан сызылып ата таң,
Мизгелләр балкый да югала.
Йә кайгы, йә бәхет, йә ләхет, йә тәхет
Бирергә яңа көн юл ала.

Кушымта:
Йортның һәр тарафын, өйнең һәр почмагын
Яктырта синең нурлы йөзең,
Йа Раббым яман күздән сине сакласын
Кулыңдагы беләзегең.

Без инде аңладык — юлларда бозлавык,
Көн саен — йә шатлык, йә бәла.
Өметемне алып яшермәкче булып,
Узган көн пәрдәсе ябыла.

Кушымта:
Йортның һәр тарафын, өйнең һәр почмагын
Яктырта синең нурлы йөзең,
Йа Раббым, бу заманнан сине сакласын
Кулыңдагы беләзегең.

*2001*

## Татар жыры

Дөнья шавы таптамасын
Татар җыры тантанасын,
Туктамасын йолдызлар яңгыры;
Моңлы җырлар, дәртле көйләр
Халык хисен җырлап сөйләр,
Һәр йортка кер, безнең Татар Җыры!

Безне һаман юллар йөртә, —
Офыкларга таба илтә,
Бураннарда җыр сузылса, җанга җылы.
Юлда чакта иптәш булыр,
Михнәтләрдән саклап калыр
Тугры юлдаш — безнең Татар Җыры!

Йөрәкләрдән йөрәкләргә,
Өметләрдән өметләргә
Җәелгәндер ал чәчәкле Яшәү Кыры;
Һәр күңелгә барып җитеп,
Татар халкын бердәм итеп
Җырлыйк, әйдә, безнең Татар Җырын!

*2001*

## Ялгыз ат

Нигә күңел болай талпына?
Бу җирсүгә, зинһар, тап чара;
Әйдәп еракларга, якты офыкларга,
Болын буйлап ялгыз ат чаба,
Болын буйлап ялгыз ат чаба.

Бу җәйләр дә үтеп китәчәк,
Көз төсләре керер бакчага;
Әллә киләчәккә, әллә балачакка
Мине дәшеп ялгыз ат чаба,
Мине дәшеп ялгыз ат чаба.

Төштәгедәй чаба ялгыз ат,
Узып бара яшел үзәнне;
Җәйге болын буйлап, язмыш белән уйнап,
Әллә минем гомер узамы?..
Әллә минем гомер узамы?..

Нигә күңел болай талпына?
Бу җирсүгә, зинһар, тап чара;
Әйдәп еракларга, якты офыкларга,
Болын буйлап ялгыз ат чаба,
Болын буйлап ялгыз ат чаба.

*2001*

## Анам җыры

Күпме еллар инде узды, юлда күпме тузан тузды...
Җәйрәп ята әле һаман иксез-чиксез яшәү кыры.
Кая барсам да ташламас туган телдә изге аваз —
Сихри моңлы анам җыры, анам җыры — бишек җыры.

Язмыш сугып еккан чакта, хәлсез ятканымда чатта,
Томан аша һаман тоям назлы күзләрнең нурын.
Каткан күңелне эретер, бар газаплардан терелтер
Мең шифалы анам җыры, анам җыры — бишек җыры.

Гомерем кояшы баегач, бу дөньядан гаип булгач,
Җәсәдемә салкын гүрдә булыр миңа соңгы урын.
Чишмә суларына тулып, урман шаулаулары булып,
Дөнья буйлап мине эзләр анам җыры — бишек җыры.

Әлли-бәлли бәү итә, балам йокыга китә...
Әлли-бәлли бәү итә, балам йокыга китә...

*2002*

## Саубуллашу көе

Кошлар төркеме кузгалды
Камышлы күлләреннән,
Төймә-төймә тезелделәр
Күкнең күк күлмәгенә.

Бизәнгән кушы урманнар, —
Көз алтыннан киенгән.
Җырлый урман, җырлый дөнья
Саубуллашу көенә.

Кабатлана табигатьтә
Бөек котылгысызлык,
Җиргә татлы сагыш сибеп
Атты көз таңы сызылып.

Шушы сагышлы көннәргә
Мин нигәдер сөенәм.
Рәхәтләнеп җырлый күңел
Саубуллашу көенә.

*1988*

## Балачакны эзләү

Төннәр җитсә түзмим, кат-кат нидер эзлим
Туган яктан килгән хатлардан.
Өстәп сагыш хисен, тагын җилләр исә
Балачагым калган яклардан.

Гомер йөгем авыр, замана болгавыр,
Үткәннәргә килә кайтасым.
Үземне танымыйм, югалттым — табалмыйм
Гүзәл әкиятләр дөньясын.

Язмыш үз итмәде, тик читкә тишмәде,
Алып китте әллә кайларга.
Күптән инде вакыт, чынбарлыкны ватып,
Балачакка кире кайтырга.

Күңел җирси, түзмим, һаман нидер эзлим...
Офыклардан нәрсә күзлимдер.
Җил сулышы белән серле аваз килә —
Балачагым мине эзлидер.

## Казан — Уфа юлы

Юлларымның азагы юк,
Җилкәмдә тормыш йөгем,
Күңел каядыр талпына —
Мин тагын юлда бүген.

К у ш ы м т а:

Ничекләр өйдә ятарсың?
Җыр белән күңел тулы.
Чакыра һаман сәфәргә
Бу Казан — Уфа юлы.

Юлларымның азагы юк,
Сөйрим тәкъдир язганны,
Казанда сагынам Өфене,
Ә Өфедә Казанны.

К у ш ы м т а:

Ничек йөрәгем йокласын?
Моң белән күңел тулы.
Мәңге тынгы бирмәс, ахры,
Бу Уфа — Казан юлы.

Ышанма дошман сүзенә,
Юк мәкерле булганым,
Бабалар бер, үзем — татар,
Башкорт — минем туганым.

К у ш ы м т а:

Ничекләр ялгыз яшәрсең?
Зар белән дөнья тулы.
Араларны якынайтсын
Бу Казан — Уфа юлы.

Көн саен керә төшемә
Кара кашң озын толым.
Арабызда дәрья түгел,
Тик Уфа — Казан юлы.

К у ш ы м т а:

Ничекләр өйдә ятарсың?
Дәрт белән күңел тулы.
Йөрәкләрне кавыштыр син,
И Казан — Уфа юлы.

Юлларымның азагы юк,
Юлда уза һәр елым,
Мәңгелеккә илтсен безне
Бормалы гомер юлы.

К у ш ы м т а:

Ничек йөрәгем йокласын?
Хис белән күңел тулы.
Киләчәккә безне дәшә
Бу Казан — Уфа юлы.

## Гомер үтәр...

Гомер үтәр,
Минем җаным галәм буйлап очып китәр...
Җирдә әле Яшәү калыр,
Таңнар атар...
Сагынырмын,
Бу гөнаһлы дөньяны мин сагынырмын,
Минем җаным бу тарафка
Кире кайтыр.

Мин кайтырмын бер мең елдан,
Тик мин куркам — сине монда таба алмам...
Синең керсез, саф, пакь җаның
Бу дөньяга кире кайтмас,
Кире кайтмас.

Минем җаным Җиһан буйлап
Сине эзләп очар елап,
Минем җаным Җиһан буйлап
Сине эзләп очар елап.

*1991*

## Сорау

Дөнья бит бу, бәла-казалар да булыр,
Янгын чыгар, мал-туарың дөрләп янар,
Йә булмаса, көтмәгәндә сулар басар.
...Шунысы мөһим: сулар кишкәч, нәрсә калыр?!

Бик ихтимал, син табынган җан иясе
Бервакытны сине кайнар утка салыр.
Әмма ләкин мәхәббәтнең чиге бардыр,
Сөю сүнгәч, күңелеңдә нәрсә калыр?!

Вакыт уза — беркемне дә санламыйдыр,
Гомернең дә котылгысыз ахыры бардыр,
Бу дөньяви мәшәкатьләр гаип булыр.
...Шунысы мөһим: үзең киткәч, нәрсә калыр?!

## Кояш баюы

Тагын яңа дөрләп шәфәкъ учагында
Бу дөньяның бөтен бар-югы;
Алдамагыз мине яшәү мәңгелек дип, —
Күргәнем бар кояш баюын.

Әле алга таба көннәр мине көтсә,
Һәр тарафка минем бар юлым;
Нигә жаның сызлый, диеп сорамагыз, —
Мин бит тоям кояш баюын.

Бигрәк сәер инде: бозлавыклы юлда
Сизмим хәзер аяк таюын;
Яңа көн иртәгә ни булса да туар, —
Бүген күрдем кояш баюын.

Менә юкка чыкты кинәт көтмәгәндә
Бу дөньяның бөтен бар-югы;
Икебез дә ярсу, тик беләсем килә —
Күрдең микән кояш баюын?..

*2003*

## Йөрәк тибеше

Төннең үзәгенә үтәр кебек —
Тынгы бирми сәгать йөреше,
Әйтерсең лә ихтыярсыз Вакыт көен көйли,
Ишетелә йөрәгем тибеше.

Төннең икенче бер тарафында
Яши минем якын бер кешем,
Төштә түгел, өндә, көне-төне ишетәмен
Аның йөрәгенең тибешен.

Мин төш күрдем: имеш, дөнья башка,
Һәркемнең бар затлы өлеше.
Көтмәгәндә, якты авазларга әверелгән
Һәр кешенең йөрәк тибеше.

Заманалар шавын санламыйча,
Инкарь итеп Вакыт йөрешен,
Мең шифалы аваз булып һаман ишетелә
Синең йөрәгеңнең тибеше.

*2003*

## Елга

Мин торам чарасыз, мин атсыз-чанасыз,
Гүя мин берүзем, атасыз-анасыз;
Бер адым атласам, сез минсез каласыз, —
Мәңгелек җебенә тагылам.

К у ш ы м т а:
Йөрәгем, шашынып, гел кага да кага,
Әсирен кызганмый, җибәрми таш кала,
Күңелем күптәннән омтылган тарафка
Болытлар тын гына агыла.

Мин бүген аңладым, моны син дә аңла:
Асылда, һәммәбез бер якка юл ала,
Гөр килгән таш кала барыбер тын кала,
Барысы да юк була, югала.

К у ш ы м т а:
Йөрәгем, шашынып, гел кага да кага,
Әсирен кызганмый, җибәрми таш кала,
Күңелем күптәннән омтылган тарафка
Болытлар тын гына агыла.

Гомернең елгасы томанга төренә,
Ярлары буенда аксыллык күренә,
Җыена микәнни кыямәт көненә,
Акса да гел кыйбла ягына?!

К у ш ы м т а:
Йөрәгем, шашынып, гел кага да кага,
Әсирен кызганмый, җибәрми таш кала,
Күңелем күптәннән омтылган тарафка
Болытлар тын гына агыла.

Һәр тамчы-мизгеле бу бөек елганың,
Ургылыш агуы түземсез елларның,
Гаҗәеп ныклыгы бу текә ярларның —
Сыярмы гап-гади акылга?!

К у ш ы м т а:
Йөрәгем, шашыныш, гел кага да кага,
Әсирен кызганмый, җибәрми таш кала,
Күңелем күптәннән омтылган тарафка
Болытлар тын гына агыла.

Мин торам чарасыз, мин атсыз-чанасыз,
Гүя мин берүзем, атасыз-анасыз,
Бер адым атласам, сез минсез каласыз,
Мәңгелек җебенә тагылам.

К у ш ы м т а:
Йөрәгем, шашыныш, гел кага да кага,
Әсирен кызганмый, җибәрми таш кала,
Күңелем күптәннән омтылган тарафка
Болытлар тын гына агыла.

*2004*

## Эчтәлек

**Уйлар уйнавы** . . . . . . . . . . . . . . 5

**Шигырьләр**
«Кычкырды төн!..» . . . . . . . . . . . . . . 42
«Шаулама! Чү! Куркытырсың...» . . . . . . . . . 43
«Үтте көн...» . . . . . . . . . . . . . . . . 44
«Аккан суның һәр тамчы-мизгеле...» . . . . . . . . 45
«Күзли галим атом ядрәләрен...» . . . . . . . . 46
«Мәхәббәт дип уйлама син бу газапны...» . . . . . . 47
Иске радио . . . . . . . . . . . . . . . . 48
Әби . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
Язалар авыл турында... . . . . . . . . . . . . 49
1991 нче ел... . . . . . . . . . . . . . . . 50
«Өй янында гарип тал агачы...» . . . . . . . . . 52
Ала алмады . . . . . . . . . . . . . . . . 53
«Тере тәнгә пычак кадагандай...» . . . . . . . . 54
«Һаман буран җирдә, һаман давыл...» . . . . . . . 55
«Ышанмыйм мин үлем барлыгына...» . . . . . . . . 56
Фахишә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
Аттылар ана этне . . . . . . . . . . . . . . 58
«Аерылышу газаплары...» . . . . . . . . . . . 59
1937 . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 60
Октябрь азагы . . . . . . . . . . . . . . . 61
«Сабыйны юаткан кебек...» . . . . . . . . . . 62
«Күбрәк сана, кәккүк, күбрәк сана...» . . . . . . . 63
«Нигә болай шомлы икән көннәр?..» . . . . . . . . 64

**Җырлар**
Нәрсә булды сиңа бүген?.. . . . . . . . . . . . 66
Татар иле . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
Газиз халкым . . . . . . . . . . . . . . . . 69

Сине югалтсам... 70
Төнге сәяхәт 72
Тәүбә 74
Син эзләмә мине... 75
Казан-кала 76
Сентябрь алмалары 78
Галия 80
Чыктым юлга 81
Апрельдә кар ява 82
Газап 83
Изге җир 84
Ярым ай 86
Каргама 87
Мосафирга эндәшү 88
Хәерле юл! 89
Җырларым-хыялларым 90
Язгы яңгыр 91
Кар яуганда 92
Юлларда бозлавык 93
Кайда син?.. 95
Азатлык 97
Көзге яфрак 99
Сафлык 100
Чулман буйларына ятты томан... 101
Татарлар килә 102
Янымда син юк икән 103
Яшенле яңгыр 105
Ашыкма 107
Сызыклар 108
Беләзек 110
Татар җыры 111
Ялгыз ат 112
Анам җыры 113

Саубуллашу көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . 114
Балачакны эзләү . . . . . . . . . . . . . . . . . 115
Казан — Уфа юлы . . . . . . . . . . . . . . . . 116
Гомер үтәр... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 118
Сорау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119
Кояш баюы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 120
Йөрәк тибеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 121
Елга . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122

Литературно-художественное издание

**Хакимханов Зульфат Зуфарович**
(Зульфат Хаким)

СЕНТЯБРЬСКИЕ ЯБЛОКИ

*Афоризмы, стихи, песни*

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *А.Р.Таһирова*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.П.Клипова*
Корректоры *Г.М.Хәбибуллина*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 31.05.2004. Форматы 70×100 $^1/_{32}$.
Офсет кәгазе. «Таймс» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 5,2+форз.0,16. Шартлы буяу-оттиск 5,93.
Нәшер-хисап табагы 3,26+форз. 0,25. Тиражы 2000. Заказ Э-394.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.